Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

23.11.2021 ел. №8

Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең
Иске Илтерәк авылында халык җыенын гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.11.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай районы, Иске Илтерәк авылы, Ленин урамы, 71а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2021 елның 06 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Илтерәк авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **беренче этабын билгеләргә**.
2. ТР, Аксубай районы, Иске Илтерәк авылы, Ленин урамы, 71а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2021 елның 06 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Илтерәк авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **икенче этабын билгеләргә**.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Иске Илтерәк авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
1) Ленин ур., Мәктәп ур.;
2) Совет ур., Яшьләр ур., Садовая ур., Гагарин ур.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада

белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән **сез риза буласызмы?**

**1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
-вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру, грунт салу, юл капламын тигезләү (грейдирование), вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш сатып алу);
- авыл эчендәге автомобиль юлларын кышкы чорда торак пунктта тоту (килешү буенча эш өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
- МТЗ-320.4 М тракторына асылмалы кар чистарткыч сатып алу.;
- электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләрен сатып алу.

**3) КККны жыю (шул исәптән аерым жыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**
- Иляшкино авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**
- ут сүндергечләр сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С. М. Маклаков